СОВЕТ ИМЕНИ ВОРОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423729,Республика Татарстан,
Мензелинский район, п.совхоза им.Воровского,
ул. Центральная, 18

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ВОРОВСКИЙ ИСЕМЕНДЭГЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423729, Татарстан Республикасы,
Минзәлә район,Воровский ис.совхоз поселогы ,
Центральный урамы,18

# КАРАР

Воровский исемендәге авыл җирлеге Советы Минзәлә районы

«27» июнь 2025 ел № 1

## Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Воровский исемендәге авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законына, 2004 елның 28 июлендәге № 45-ЗРТ «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы законына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Воровский исемендәге авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Воровский исемендәге авыл җирлеге Советының 2023 елның 26 декабрендәге №1 карарына «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Воровский исемендәге авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1 Уставның 5 статьясындагы 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 21 пункт өстәргә:
«21) "Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге №112-ФЗ Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыру».

1.2. Уставны 7.1. маддәсе белән түбәндәгечә тулыландырырга:
«7.1. Җирлекнең җирле үзидарә органнарының халыкара һәм тышкы икътисади бәйләнешләре

Җирлекнең җирле үзидарә органнары халыкара һәм тышкы икътисади элемтәләрне Федераль закон № 131-ФЗ һәм Татарстан Республикасы Законы № 45-ЗРТ белән билгеләнгән формаларда һәм тәртиптә гамәлгә ашыра.

1.3. 19 мадденең 7 өлешендә Устав сүзләрен «әлеге Устав һәм (яки)» чыгарып ташларга;

1.4. 41 нче мадденең 1 нче өлешен түбәндәге эчтәлекле 14 нче пункт белән тулыландырырга:
«14) аның чит ил агенты статусын алуы.»;

1.5. Уставның 23 маддәсенең 3 өлешен түбәндәге эчтәлекле җөмләләр белән тулыландырырга:
Әгәр дә торак пунктта сайлау хокукына ия булган халыкның яртысыннан артыгы бер үк вакытта катнаша алмый икән, муниципаль берәмлек уставына ярашлы рәвештә, әлеге торак пункт кергән муниципаль берәмлекнең гражданнар җыены этаплап үткәрелә, һәм ул гражданнар җыены үткәрү турында карар кабул ителгән көннән башлап бер айдан артык булмаган вакыт эчендә үткәрелә. Моңа кадәр гражданнар җыенында катнашкан затлар алдагы этапларда тавыш бирүдә катнашмый. Әгәр дә аның өчен гражданнар җыены катнашучыларының яртысыннан күбрәге тавыш биргән булса,гражданнар җыены карары кабул ителгән дип санала.

1.6. 50 нче мадденең 1 нче өлешенең 6 нчы пунктының өченче абзацында "күрсәтелгән кагыйдәләр белән" сүзләрен "Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре белән" сүзләре белән алыштырырга.

1.7. 72 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"72 нче статья. Муниципаль норматив хокукый актларны рәсми рәвештә халыкка җиткерү һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе

1. Җирлек Советы карарлары, әгәр башкасы карар белән билгеләнмәгән булса, җирлек башлыгы имзалаган көннән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Җирлек Советынын салымнар һәм җыемнар турындагы норматив хокукый актлары Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә үз көченә керә.

Җирлек Советының җирлек уставын кабул итү яисә әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турындагы карарлары Федераль законда, әлеге Уставта билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.

2. Җирлек башлыгынын, Җирле үзидарәнең башка вазыйфаи затларының хокукый актлары, әгәр актларда башкасы билгеләнмәгән булса, аларга кул куелган көннән үз көченә керә.

3. Кеше һәм гражданның хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы, гамәлгә куючысы муниципаль берәмлек була торган оешмаларның хокукый статусын билгели торган муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр алар рәсми халыкка игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

4. Муниципаль норматив хокукый актны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүне халыкка җиткерү аларның:

1) тулы текстны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында рәсми бастырып чыгару (https://pravo.tatarstan.ru; массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында ЭЛ № ФС77-60244 таныклык бирелгән 17.12.2013 элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт

(Роскомнадзор) яисә Минзәлә районының «Минзәлә " газетасында; массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында ПИ № ФС7-4760 таныклык бирелде 30.11.2007 массакүләм коммуникацияләр һәм мәдәни мирасны саклау өлкәсендәге законнарның үтәлешен күзәтчелек итү буенча федераль хезмәтнең Идел буе идарәсе);

2) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Минзәлә муниципаль районы сайтында урнаштыру https://menzelinsk.tatarstan.ru/;

3) Татарстан Республикасы, Минзәлә районы, Воровский исемендәге совхоз бистәсе, Үзәк урам, 18 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру.

5. Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның Рәсми порталына гражданнарның керүен тәэмин итү өчен, Минзәлә районы, Воровский исемендәге совхоз бистәсе, Үзәк урам, 18 йорт адресы буенча урнашкан "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәренә тоташу пунктлары эшли.

6. Җирлек Советының җирлек бюджеты турында, аны үтәү турындагы хисап хакында, җирле салымнарны һәм җыемнарны билгеләү турында карарлары, җирлек Советы Регламенты, җирлек Советы кабул иткән башка муниципаль норматив хокукый актлар, җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр,федераль закон белән таратылуы чикләнгән белешмәләр булган муниципаль норматив хокукый актлардан яисә аларның аерым нигезләмәләреннән тыш, алар имзаланган көннән алып җиде көн эчендә рәсми рәвештә халыкка игълан ителергә тиеш.

7. Әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелмәгән муниципаль хокукый актлар, әгәр актның үзендә башкасы билгеләнмәгән булса, аларга имза салынган көннән үз көченә керә.

8. Һәр муниципаль хокукый актта аның реквизитлары булырга тиеш: исеме, аңа кул кую датасы (җирлек Советы кабул иткән хокукый актлар өчен - шулай ук аны җирлек Советы кабул иткән дата), теркәү номеры, хокукый актка кул куйган вазыйфаи зат исеме, мөһер.

9. Муниципаль хокукый актларны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләрне рәсми бастырудан тыш, халыкка җиткерү өчен мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Интернет» домен исемнәре һәм массакүләм мәгълүмат чаралары буларак теркәлү мәгълүматлары күрсәтелгән периодик басма һәм челтәр басмалары исемлеге, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Воровский авыл җирлеге Башлыгының хокукый акты бастыру юлы белән халыкка җиткерелә.

10. Муниципаль норматив хокукый актлар, шул исәптән хокукый актлар карары рәвешендә рәсмиләштерелгәннәр, җирле референдумда (гражданнар җыелышында) кабул ителгәннәр, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар реестрына кертелергә тиеш, аның оештыру һәм алып бару тәртибе Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

1.8. Уставның 74 статьясының 1 өлешенең 5 пунктында 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясының 4 өлешенә сылтаманы чыгарып ташларга;

1.9. Уставның 75 нче маддәсенә 4 нче өлешне түбәндәгечә өстәргә:
«4. Авыл җирлеге башкарма комитеты муниципаль милектә булган электр челтәре хуҗалыгы объектларын, Татарстан Республикасы чикләрендә эшләүче системалы территориаль челтәр оешмасына яки территориаль челтәр оешмасына, Россия Федерациясенең электроэнергетика турындагы законнары белән билгеләнгән очракларда, тәртиптә һәм шартларда, бушка милеккә һәм файдалануга тапшыруны гамәлгә ашыра.

1.10. Уставның 80 нче маддәнең 6 нчы өлешендә «Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм әлеге Устав» сүзләрен «Авыл җирлеге советының муниципаль норматив хокукый актлары» сүзләре белән алыштырырга.

1.11. 80 маддәнең 12 өлешендә "Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы законнары" сүзләрен "Җирлек Советының муниципаль норматив хокукый актлары" сүзләре белән алыштырырга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрергә.

3. Әлеге карар дәүләт теркәвеннән һәм рәсми рәвештә бастырылганнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы Минзәлә
муниципаль районы Воровский
исемендәге авыл җирлеге башлыгы урынбасары
муниципаль Совет
Совет рәисе В.П. Елхов